# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге составына керүче Комаровка торак пунктында 2025 елга үзара салым кертү турында

«19» ноябрь, 2024 ел №7

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нче статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең Комаровка торак пунктында узган гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Комаровка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында катнашканнарның тол хатыннары, СВО да катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2025 елда 800(сигз йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Комаровка торак пунктында Беренче Май урамындагы юлларны вак таш түшәп ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, салу, эшләр өчен килешү буенча түләү); Комаровка торак пунктында юлларны кардан чистарту))
- Комаровка торак пунктында урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны (яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру, эшләр өчен килешү буенча түләү) ремонтлау).

3. Әлеге карарны Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе Е.М.Михайлова